Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З.Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан
кертелә

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

1 статья

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 статьяның $7^1$ пунктында «(яисә)» сүзен төшереп калдырырга, «референдумны оештыручы комиссия» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 26 статьяның 5 пунктында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Референдумда катнашучылар исемлекләрен төзү өчен референдумда катнашучылар турындагы белешмәләр сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны дәүләт теркәве (исәпкә алуы) системасыннан файдаланып формалаштырыла»;

3) 34 статьяның 5 пунктында «шул исәптән сүзләрен «шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

4) 44 статьяда:

а) 9 пунктта «шәхсән булмаганда» сүзләрен «, Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, шәхсән килмичә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 10пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Референдум үткәргәндә әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән счетны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан

Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Референдум фондының махсус счетын шәхсән килмичә (дистанцион) ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкы һәм җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә), террорчылыкны, экстремистлык эшчәнлеген финанслауга һәм күпләп юк итү коралларын таратуны финанслауга каршы көрәш функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Референдум фонды акчалары керү һәм бу акчаларны тоту турында, шул исәптән һәр операция буенча, исәп алып бару һәм хисап бирү тәртибе һәм рәвешләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

5) 45 статьяда:

а) 8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе референдумда тавыш бирү көненә кадәр референдум фондларына акчалар керү һәм аларның тотылуы турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына даими рәвештә белешмәләр урнаштыра. Түбәндәге белешмәләр һичшиксез урнаштырылырга тиеш:»;

б) $9^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$9^1$. Әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән финанс хисабы күчермәсе, аны алган көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.»;

6) 49 статьяның 9 пунктында «көненә (беренче көненә) кадәр бер көннән» сүзләрен «көненә (беренче көненә) кадәрге көннән» сүзләренә алмаштырырга;

7) 50 статьяның 14 пунктында «Электрон тавыш бирү үткәргәндә» сүзләреннән соң «референдумда катнашучы референдумда катнашу хокукына ия референдум округы чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

8) 52 статьяның $1^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән электрон рәвештә төзелергә мөмкин. Бу очракта участок комиссиясенең тавыш бирү йомгакларын билгеләү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

9) 53 статьяда:

а) 30 пунктның беренче абзацында «яисә электрон тавыш бирү комплексларыннан» сүзләрен һәм «һәм электрон тавыш бирү комплекслары» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 33 пунктта «, электрон тавыш бирү комплексларыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 54 статьяда:

а) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: «Беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазь чыганакта бастырып чыгару юлы белән әзерләнә һәм Федераль законда билгеләнгән тәртиптә таныклана.»;

б) түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«3[1]. Тавыш бирү йомгаклары турында җыелма таблица һәм беркетмә Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән электрон рәвештә төзелергә мөмкин. Бу очракта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең тавыш бирү йомгакларын, референдум нәтиҗәләрен билгеләү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.».

2 статья

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяның 7[1] пунктында «(яисә)» сүзен төшереп калдырырга, слова «референдум оештыручы комиссия» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 27 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Референдумда катнашучылар исемлекләрен төзү өчен референдумда катнашучылар турындагы белешмәләр сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны дәүләт теркәве (исәпкә алуы) системасыннан файдаланып формалаштырыла»;

3) 36 статьяның 5 пунктында «шул исәптән» сүзләрен «шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

4) 46 статьяда:

а) 9 пунктта «шәхсән булмаганда» сүзләрен «, Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, шәхсән килмичә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 11пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Референдум үткәргәндә әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән счетны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Референдум фондының махсус счетын шәхсән килмичә (дистанцион) ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкы һәм җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә), террорчылыкны, экстремистлык эшчәнлеген финанслауга һәм күпләп юк итү коралларын таратуны финанслауга каршы көрәш функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Референдум фонды акчалары керү һәм бу акчаларны тоту турында, шул исәптән һәр операция буенча, исәп алып бару һәм хисап бирү тәртибе һәм рәвешләре Татарстан Республикасы территория комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

5) 47 статьяда:

а) 8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Территория комиссиясе референдумда тавыш бирү көненә кадәр референдум фондларына акчалар керү һәм аларның тотылуы турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына (үзенең сайты булмаган очракта – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең рәсми сайтына) даими рәвештә белешмәләр урнаштыра. Түбәндәге белешмәләр һичшиксез урнаштырылырга тиеш:»;

б) $9^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$9^1$. Әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән финанс хисабы күчермәсе, аны алган көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча территория комиссиясе тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына, үзенең сайты булмаган очракта – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең рәсми сайтына урнаштырыла.»;

6) 51 статьяның 8 пунктында «көненә (беренче көненә) кадәр бер көннән» сүзләрен «көненә (беренче көненә) кадәрге көннән» сүзләренә алмаштырырга;

7) 52 статьяның 14 пунктында «Электрон тавыш бирү үткәргәндә» сүзләреннән соң «референдумда катнашучы референдумда катнашу хокукына ия референдум округы чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

8) 54 статьи $1^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә референдумны оештыручы комиссия карары белән электрон рәвештә төзелергә

мөмкин. Бу очракта участок комиссиясенең тавыш бирү йомгакларын билгеләү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

9) 55 статьяда:

а) 30 пунктның беренче абзацында «яисә электрон тавыш бирү комплексларыннан», «, электрон тавыш бирү комплексларыннан» һәм «һәм электрон тавыш бирү комплекслары» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) $30^3$ пунктта «электрон тавыш бирү комплексларыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 56 статьяда:

а) 7 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазь чыганакта бастырып чыгару юлы белән әзерләнә һәм «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә таныклана.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$пункт өстәргә:

«$7^1$. Тавыш бирү йомгаклары турында җыелма таблица һәм беркетмә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә референдумны оештыручы комиссия карары белән электрон рәвештә төзелергә мөмкин. Бу очракта тиешле комиссиянең тавыш бирү йомгакларын, референдум нәтиҗәләрен билгеләү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.».

**3 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 33 (I өлеш), № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 7 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 16 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацта «участок комиссияләре төзелә» сүзләрен «шул исәптән төрле дәрәҗәдәге сайлауларны әзерләү һәм уздыру вәкаләтләрен билгеле бер территориядә берьюлы үтәүче участок комиссияләре төзелә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 22 статьяның $3^1$ өлешендә слово «(яисә)» сүзен төшереп калдырырга,

«сайлауларны оештыручы комиссия» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 29 статьяның 7 өлешендә «белешмәләрне муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгы төзи һәм төгәлләштерә» сүзләрен «белешмәләр сайлаучылар исемлекләрен төзү өчен сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны дәүләт теркәвенә алу (исәпкә алу) системасыннан файдаланып булдырыла» сүзләренә алмаштырырга;

5) 32 статьяның 2 өлешендә «исем» сүзеннән соң «яисә юридик затларның бердәй дәүләт реестрында күрсәтелгән исем» сүзләрен өстәргә;

6) 40 статьяда:

а) 2 өлешнең $1^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$) иҗтимагый берләшмәләрне теркәү өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, аның территориаль органы тарафыннан бирелгән сайлау берләшмәсен дәүләт теркәве турында документның нотариаль таныкланган күчермәсен яисә сайлау берләшмәсе турында язманы юридик затларның бердәй дәүләт реестрында кертүне раслый торган документны, әгәр сайлау берләшмәсе юридик зат булмаса, шулай ук аны төзү турындагы карарны;»;

б) 5 өлештә «алган көннән соң» сүзләрен «алган көннән соң килүче» сүзләренә алмаштырырга;

7) 41 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) иҗтимагый берләшмәләрне теркәү өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, аның территориаль органы тарафыннан бирелгән сайлау берләшмәсен дәүләт теркәве турында документның нотариаль таныкланган күчермәсен яисә сайлау берләшмәсе турында язманы юридик затларның бердәй дәүләт реестрында кертүне раслый торган документны, әгәр сайлау берләшмәсе юридик зат булмаса, шулай ук аны төзү турындагы карарны;»;

8) 42 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) иҗтимагый берләшмәләрне теркәү өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, аның территориаль органы тарафыннан бирелгән сайлау берләшмәсен дәүләт теркәве турында документның нотариаль таныкланган күчермәсен яисә сайлау берләшмәсе турында язманы юридик затларның бердәй дәүләт реестрында кертүне раслый торган документны, әгәр сайлау берләшмәсе юридик зат булмаса, шулай ук аны төзү турындагы карарны;»;

9) 58 статьяда:

а) 7 өлештә «шул исәптән» сүзләрен «шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

б) $10^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$10^{1}$. Сайлаулар үткәргәндә агитация материалларында физик затның сурәтеннән файдалану һәм (яисә) аның тавышын яңгырату бары тик түбәндәге очракларда гына рөхсәт ителә:

а) сайлау берләшмәсе тарафыннан тиешле сайлауларда алар күрсәткән кандидатның (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында), билгесез затлар даирәсе арасыннан кандидатны (кандидатларны) кертеп, сурәтеннән файдаланганда һәм (яисә) тавышын яңгыратканда;

б) кандидат үз сурәтләреннән файдаланганда һәм (яисә) үз тавышын яңгыратканда, шул исәптән кандидат сурәтеннән билгесез затлар даирәсе арасыннан;

в) Россия Федерациясе гражданы булган һәм 18 яшькә җиткән башка затның, мондый затның язма ризалыгы булганда һәм мондый затның әлеге Кодексның 3 статьясындагы 3 өлеше, 4 статьясындагы 4, 5, 6, $6^{4}$ өлешләре белән каралган чикләүләре булмаса, сурәтеннән файдаланганда һәм (яисә) тавышын яңгыратканда.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $10^{1-1}$ өлеш өстәргә:

«$10^{1-1}$. Агитация материалында кешенең, шул исәптән уйлап чыгарылган яисә вафат булган, сурәтеннән (образыннан) файдалану һәм (яисә) тавышын яңгырату, мәгълүмат технологияләрен кулланып барлыкка китерелгән сурәтне яисә аудиоязманы кертеп, рөхсәт ителми, әлеге статьяның $10^{1}$ өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш.»;

г) $10^{2}$ өлештә «$10^{1}$ өлешендә» сүзләрен «$10^{1}$ өлешендәге «а» һәм «б» пунктларында» сүзләренә алмаштырырга, «сурәтләрдән файдалану» сүзләреннән соң «һәм (яисә) тавышын яңгырату» сүзләрен өстәргә;

д) түбәндәге эчтәлекле $10^{2-1}$ һәм $10^{2-2}$ өлешләр өстәргә:

«$10^{2-1}$. Әлеге статьяның $10^{1}$ өлешендәге «в» пунктында күрсәтелгән ризалыкны раслый торган, шулай ук әлеге Кодексның 3 статьясындагы 3 өлеше, 4 статьясындагы 4, 5, 6, $6^{4}$ өлешләре белән каралган чикләүләр булмауны раслый торган документ әлеге Кодексның 64 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән материаллар белән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан расланган рәвештә сайлау комиссиясенә тапшырыла. Агитация материалы телерадиотапшырулар оешмасы каналында урнаштырылган очракта, күрсәтелгән документ агитация материалы күчермәсе һәм әлеге Кодексның 60 статьясындагы $11^{1}$ өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат белән сайлау комиссиясенә тапшырыла.

$10^{2-2}$. Агитация материалларында чит ил агенты белән аффилиацияләнгән физик затның сурәтеннән файдалану һәм (яисә) тавышын яңгырату мондый физик затның чит ил агенты белән аффилиацияләнгән булуы күрсәтелергә тиеш.»;

е) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Сайлау комиссиясе тарафыннан теркәлгән кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия, тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, үзенең сайлау алды программасын кимендә бер дәүләт яисә муниципаль (сайлауларның дәрәҗәсенә карап) вакытлы матбугат басмасында бастырып чыгара яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең сайтында (башка сайтта) урнаштыра, шулай ук күрсәтелгән срок эчендә сайлауларны оештыручы

сайлау комиссиясенә тиешенчә күрсәтелгән публикациянең күчермәсен тапшыра һәм (яисә) мондый программа урнаштырылган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайт адресын хәбәр итә.

Сайлау алды программасын вакытлы матбугат басмасында бастырып чыгарганда «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Кодекс нигезендә сайлау берләшмәләренә, кандидатларга бирелә торган түләүсез матбугат мәйданы файдаланыла йә мондый публикациягә сәяси партиянең сайлау фонды, шул сәяси партия күрсәткән кандидатның сайлау фонды акчаларыннан түләнә.»;

10) 60 статьяның $11^1$ өлешендә «сурәте файдаланылу» сүзләреннән соң «(тавышын яңгырату)» сүзләрен өстәргә)»;

11) 64 статьяда:

а) 6 өлештә «7, 8, һәм $9^1$ һәм $10^1$ өлешләрендә» сүзләрен «7, 8, $9^1$, $10^1$,$10^{1-1}$ һәм $10^{2-2}$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә «10,» цифрасыннан соң «$10^{2-1}$,» цифрларын өстәргә;

12) 69 статьяда:

а) 1 өлештә «шәхсән булмаганда (дистанцион)» сүзләрен «, Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, шәхсән килмичә (дистанцион)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән счетларны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Махсус сайлау счетларын шәхсән килмичә (дистанцион) ачу, алып бару һәм ябу тәртибе Россия Федерациясе Үзәк банкы һәм җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә), террорчылыкны, экстремистлык эшчәнлеген финанслауга һәм күпләп юк итү коралларын таратуны финанслауга каршы көрәш функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Сайлау фондларына акчалар керү һәм бу акчаларның тотылуы турында, шул исәптән һәр операция буенча, исәп алып бару һәм хисап бирү тәртибе һәм рәвешләре тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

13) 70 статьяда:

а) 8 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Тиешле комиссия сайлауларда тавыш бирү көненә кадәр сайлау фондларына акчалар керү һәм аларның тотылуы турындагы белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына (мондый сайт булмаганда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең рәсми сайтына) даими рәвештә урнаштыра. Түбәндәге белешмәләр һичшиксез урнаштырылырга тиеш:»;

б) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән финанс хисапларының күчермәләре, аларны алган көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, комиссияләр тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзләренең рәсми сайтларына, ә мондый сайт булмаганда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең рәсми сайтына даими рәвештә урнаштырыла.»;

14) 75 статьяның 16 өлешендә «көненә (беренче көненә) кадәр бер көннән» сүзләрен «көненә (беренче көненә) кадәрге көннән» сүзләренә алмаштырырга;

15) 76 статьяның 17 өлешендә «мөмкинлеге» сүзеннән соң «сайлаучы актив сайлау хокукына ия булган тиешле сайлау округы чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

16) 78 статьяның $1^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Тавыш бирү йомгаклары турында сайлау комиссиясе беркетмәсе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сайлауларны оештыручы комиссия карары буенча электрон рәвештә төзелергә мөмкин. Бу очракта сайлау комиссиясенең тавыш бирү йомгакларын билгеләү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

17) 79 статьяда:

а) 31 өлешнең беренче абзацында «яисә электрон тавыш бирү комплексларыннан» сүзләрен, «, электрон тавыш бирү комплексларыннан» һәм «һәм электрон тавыш бирү комплекслары» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) $31^3$ өлештә «, электрон тавыш бирү комплексларыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

18) 80 статьяда:

а) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: «Беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазь чыганакта бастырып чыгару юлы белән әзерләнә һәм «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә таныклана.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$пункт өстәргә:

«$7^1$. Тавыш бирү йомгаклары турында җыелма таблица һәм беркетмә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә

сайлауларны оештыручы комиссия карары белән электрон рәвештә төзелергә мөмкин. Бу очракта тиешле комиссиянең тавыш бирү йомгакларын, сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 2 маендагы 130-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә әзерләнде.

Закон проектының максаты – Татарстан Республикасы Сайлау кодексын, «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы һәм «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарын күрсәтелгән Федераль законга туры китерү.

Закон проекты белән үзгәрешләр кертелә, алар нигезендә муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгының сайлаучылар, референдумда катнашучылар турында белешмәләрне булдыру һәм төгәлләштерү буенча бурычы төшереп калдырыла. Әлеге белешмәләр сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан – сайлаучылар, референдумда катнашучылар турында белешмәләр булган үзәкләштерелгән мәгълүмат ресурсыннан (Сайлаучылар, референдумда катнашучылар регистры) файдаланып төзеләчәк, ул реаль вакыт режимында төгәлләштерелә.

Закон проектында күрсәтелгәнчә, сайлаулар үткәргәндә сайлау комиссиясе тарафыннан теркәлгән кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия үзенең сайлау алды программасын кимендә бер дәүләт яисә муниципаль (сайлауларның дәрәҗәсенә карап) вакытлы матбугат басмасында бастырып чыгара яисә аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында (башка сайтта) урнаштыра ала. Шулай ук сәяси портиянең сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә алда телгә алынган мәгълүматның яисә хәбәрнең күчермәсен, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шундый программа урнаштырылган сайтның адресын тапшыру бурычы билгеләнә.

Закон проектында тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләрне һәм җыелма таблицаларны, мондый беркетмәнең күчермәсен кәгазь чыганакта мәҗбүри бирү шарты белән, электрон рәвештә төзү мөмкинлеге беркетелә. Йомгаклау документларын электрон рәвештә төзү турындагы карарны сайлауларны, референдумны оештыручы сайлау комиссиясе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә кабул итәчәк. Шул ук вакытта тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне һәм җыелма таблицаларны кәгазь чыганакларда рәсмиләштерү процедурасы саклана.

Кандидатларның, сайлау берләшмәләренең финанс хисапларын, шулай ук вакытлы матбугат басмаларында сайлау фондларына акчаларның керүе һәм тотылуы турындагы белешмәләрне бастырып чыгару турындагы норма урынына аларны «Интернет» челтәрендәге сайлау комиссияләре сайтларында мәҗбүри урнаштыру беркетелә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.